КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 сентябрь г.Казань № 820

2020 – 2022 елларга һәм 2024 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы, 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проекты турында

2020 – 2022 елларга һәм 2024 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы, 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проекты турындагы докладларны тыңлаганнан соң һәм алар буенча фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 – 2022 елларга һәм 2024 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын расларга.

2. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразын, 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проектын игътибарга алырга.

3. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына «2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын, әлеге закон проекты белән бер үк вакытта кертелә торган документларны һәм материалларны теркәп, 2019 елның 30 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карап тикшерүгә билгеләнгән тәртиптә кертергә.

4. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына «2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын 2019 елның 30 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карап тикшерүгә билгеләнгән тәртиптә кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин